КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 23 июнь г.Казань № 420

Муса Җәлил исемендәге республика
премиясен бирү турында

Муса Җәлил исемендәге республика премиясен бирү комитеты утырышы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 – 2017 еллар конкурсы нәтиҗәләре буенча Муса Җәлил исемендәге республика премиясен түбәндәгеләргә бирергә:

«Татарстан Республикасының иҗади яшьләре академиясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы коллективына – Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруга зур өлеш керткән өчен;

Айматов Рәмис Кыям улына, шагыйрьгә, – иҗади яшьләр белән озак еллык нәтиҗәле эш өчен;

Пискунов Артем Олеговичка, Сәләхова Резеда Нурислам кызына, «К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең драма артистларына – театр сәнгате өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен;

Шәрипов Марат Сабит улына, җәмәгать эшлеклесенә – актив иҗтимагый-агарту эшчәнлеге һәм яшьләр программаларын тормышка ашыруга зур өлеш керткән өчен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\420.docx